| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**19.10.2022** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2777** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 ноябрендәге 2141 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының « Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау хакында» 2020 елның 10 ноябрендәге 2141 нче карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре салым чыгымнары исемлеге төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында (2021 елның 17 маендагы 1042 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 пунктта «,муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 15 пунктның 2 абзацында «,муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ташламаларга хокуклы булган түләүчеләр саны һәм ташламалардан кулланугa потенциаль хокукы булган түләүчеләр саны яисә 5 еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана торган, бирелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы»;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 15 абзац өстәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан ташламалар бирелгән түләүчеләрнең ихтыяҗын бәяләүне уздыру максатларында ташламалар таләп ителгән әлеге пунктның 3 абзацында күрсәтелгән нисбәтнең минималь күрсәткече билгеләнергә мөмкин, бу очракта ташлама кирәкле дип таныла».

1.5. түбәндәге эчтәлекле 18(1) пункт өстәргә:

«18(1). Кирәк булганда, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма

комитеты муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүнең өстәмә критерийларын билгели ала».

1.6. түбәндәге эчтәлекле 19(1) пункт өстәргә:

«19(1). Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләүне муниципаль берәмлекнең техник салым чыгымнарына карата үткәрмәскә рөхсәт ителә».

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В.Старостин